**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 25 февралендәге 572 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 12 августындагы 3344 номерлы карары белән расланган «Казан шәһәренең Киров районындагы «Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» территорияләре өчен су белән тәэмин итүнең магистраль челтәрләре» линия объекты территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, Россия Федерациясе субъектларының вәкаләтле башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 ноябрендәге 933 номерлы «Раслау турындагы карар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне ызанлау проектлары, территорияне планлаштыруның мондый проектларына һәм территорияне ызанлау проектларына үзгәрешләр кертү җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар уздырмыйча раслана торган очракларны билгеләү турында»гы карарына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 11 августындагы 2591 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның

12 августындагы 3344 номерлы карары белән расланган «Казан шәһәренең Киров районындагы «Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» территорияләре өчен су белән тәэмин итүнең магистраль челтәрләре» линия объекты территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында»гы карарына таянып, **карар бирәм:**

1.Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 12 августындагы 3344 номерлы карары белән расланган «Казан шәһәренең Киров районындагы «Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» территорияләре өчен су белән тәэмин итүнең магистраль челтәрләре» линия объекты территориясен планлаштыру проектына, әлеге карарның кушымтасы нигезендә территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслау юлы белән, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, планлаштырылган линия объектын урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәренең җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның  25 февралендәге
572 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 12 августындагы 3344 номерлы карары белән расланган «Казан шәһәренең Киров районындагы «Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» территорияләре өчен су белән тәэмин итүнең магистраль челтәрләре» линия объекты территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Икенче абзацта «(1-8 битләр)» сүзләрен «(1-5 битләр)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең сызымын әлеге үзгәрешләргә 1 номерлы кушымта нигезендәге редакциядә бирергә.


3.Линия объектын урнаштыру турындагы нигезләмәне әлеге үзгәрешләргә 2 номерлы кушымта нигезендәге редакциядә бирергә.

___

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның
12 августындагы 3344 номерлы карары белән
расланган «Казан шәһәренең Киров районындагы
«Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон»
территорияләре өчен су белән тәэмин итүнең
магистраль челтәрләре» линия объекты территориясен
планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә
1 номерлы кушымта

# I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең сызымы

(1 бит)




**Шартлы билгеләр:**

- планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре;

- гамәлдәге кызыл линияләр

**Линия объектларын план буенча урнаштыру зонасы чикләре:**
- хуҗалык-эчә торган һәм янгынга каршы суүткәргеч (В1)

**Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре:**
- суүткәргеч насос станциясе (СНС)


**Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары номерлары:**
- хуҗалык-эчә торган һәм янгынга каршы суүткәргеч (В1)

о1

- планлаштыру структурасының гамәлдәге элементларының чикләре;

- планлаштыру структурасының планлаштырыла торган элементларының чикләре

(2 бит)




**Шартлы билгеләр:**

- планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре;

- гамәлдәге кызыл линияләр

**Линия объектларын план буенча урнаштыру зонасы чикләре:**

- хуҗалык-эчә торган һәм янгынга каршы суүткәргеч (В1)

**Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре:**

- суүткәргеч насос станциясе (СНС)

**Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары номерлары:**

о1 - хуҗалык-эчә торган һәм янгынга каршы суүткәргеч (В1)


- планлаштыру структурасының гамәлдәге элементларының чикләре;

- планлаштыру структурасының планлаштырыла торган элементларының чикләре

Схема расположения листов



(3 бит)




**Шартлы билгеләр:**

- планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре;

- гамәлдәге кызыл линияләр

**Линия объектларын план буенча урнаштыру зонасы чикләре:**

- хуҗалык-эчә торган һәм янгынга каршы суүткәргеч (В1)

**Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре:**

- суүткәргеч насос станциясе (СНС)


**Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары номерлары:**

о1 - хуҗалык-эчә торган һәм янгынга каршы суүткәргеч (В1)


- планлаштыру структурасының гамәлдәге элементларының чикләре;

- планлаштыру структурасының планлаштырыла торган элементларының чикләре

Схема расположения листов



(4 бит)




**Шартлы билгеләр:**

- планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре;

- гамәлдәге кызыл линияләр

**Линия объектларын план буенча урнаштыру зонасы чикләре:**

- хуҗалык-эчә торган һәм янгынга каршы суүткәргеч (В1)

**Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре:**

- суүткәргеч насос станциясе (СНС)


**Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары номерлары:**

о1 - хуҗалык-эчә торган һәм янгынга каршы суүткәргеч (В1)

- планлаштыру структурасының гамәлдәге элементларының чикләре;

- планлаштыру структурасының планлаштырыла торган элементларының чикләре

Схема расположения листов



(5 бит)




Линия совмещения с листом 4
Линия совмещения с листом 5

**Шартлы билгеләр:**

- планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре;

- гамәлдәге кызыл линияләр

**Линия объектларын план буенча урнаштыру зонасы чикләре:**

- хуҗалык-эчә торган һәм янгынга каршы суүткәргеч (В1)

**Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре:**

- суүткәргеч насос станциясе (СНС)

**Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары номерлары:**

о1 - хуҗалык-эчә торган һәм янгынга каршы суүткәргеч (В1)

- планлаштыру структурасының гамәлдәге элементларының чикләре;

- планлаштыру структурасының планлаштырыла торган элементларының чикләре

Схема расположения листов



Казан шәһәре Башкарма комитетының
2024 елның 12 августындагы 3344 номерлы
карары белән расланган «Казан шәһәренең
Киров районындагы «Хәрби шәһәрчек-32»
һәм «Экорайон» территорияләре өчен су
белән тәэмин итүнең магистраль челтәрләре»
линия объекты территориясен планлаштыру
проектына кертелә торган үзгәрешләргә
2 номерлы кушымта

**Линия объектын урнаштыру турында нигезләмә**

**Урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектының исеме, төп характеристикалары һәм билгеләнеше һәм урнаштыру өчен планлаштырыла торган линия объектларының билгеләнеше**

**Су белән тәэмин итүнең мәйданчыктан тыш челтәрләре (хуҗалык-эчә торган һәм янгынга каршы сусүткәргеч–В1)**

Тоташтыру ноктасы – Боевая урамындагы 2Ø1200 мм диаметрлы су белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру урыны. Тоташтыру нокталарында суүткәргеч челтәрендәге басым – су баганасында 30 метр.

Суүткәргеч челтәрләре тоташтыру ноктасыннан алып суүткәргеч насос станциясенә кадәр гомуми озынлыгы 4270 м булган dн710 диаметрлы ике җепкә салынган (эш проектлаштыру стадиясендә төгәлләштерелә). Тоташтыру нокталарында ВК15 һәм ВК16 суүткәргеч камералары урнаштырылган.

Салу ысулы:

- юллар һәм яхшыртылган өслекләр астында траншеясыз ысул белән салу (бүлеп бирелгән юлның киңлеге күчәрнең һәр ягында 5 м тәшкил итә);

- ачык ысул белән (бүлеп бирелгән юлның киңлеге күчәрдән һәр якка 10 м га тигез).

Төзелеш өчен туры линияле кишәрлекләр бүлеп бирелә.

31.13330.2021 кагыйдәләр җыелмасының 7.4 пункты нигезендә проектлана торган берләштерелгән хуҗалык-янгынга каршы суүткәргеч су бирүне тәэмин итү дәрәҗәсе буенча I категориягә, шулай ук Электр җайланмаларын урнаштыру кагыйдәләре буенча электр белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын тәэмин итү буенча I категориягә карый.

Җаваплылык дәрәҗәсе буенча суүткәргеч I класслы суүткәргечкә карый. Утка чыдамлылык дәрәҗәсе нормалаштырылмый.

**Суүткәргеч насос станциясе**

Су үткәрү насос станциясе «Экорайон» һәм «Хәрби шәһәрчек-32» торак районнарыннан кулланучылар өчен суүткәргеч суларын ташуны арттыру максатыннан проект белән каралган.

Су үткәрү насос станциясенең урнашу урыны әлеге объектны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 20 октябрендәге 3561 номерлы карары белән расланган «Экорайон» территориясен планлаштыру проектын урнаштыру өчен каралган зонада билгеләнде.

Хуҗалык-эчү өчен, янгынга каршы ихтыяҗларга су бирү белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе буенча проектлана торган суүткәргеч насос станциясе ышанычлылык буенча I категориягә карый, җитештерүчәнлек – 13 954,53 куб.м/сут (максималь сәгатьлек чыгым – 1291,59 куб.м/сәг), бу «Экорайон» һәм «Хәрби шәһәрчек-32» территорияләрен су белән тәэмин итү буенча исәпләнгән гомуми йөкләнешкә туры килә.

Проектлана торган объектның төзелеш төре – яңа төзелеш. Объектны бер этапта төзү каралган.

Төзелеш гамәлдәге коммуникацияләргә кагылмый, алар күчерелергә һәм үзгәртеп корылырга тиеш түгел.

## Территорияләрендә линия объектын план буенча урнаштыру зоналары билгеләнә торган субъектлар исемлеге

Проект чикләрендәге мәйдан 159 830 кв.м тәшкил итә. «Казан шәһәренең Киров районындагы «Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» территорияләре өчен су белән тәэмин итүнең магистраль челтәрләре» линия объектын план буенча урнаштыру зонасы Көнчыгыш Европа тигезлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендә, Идел елгасы үзәнендә, аның сул ярында урнашкан.

Проектлаштыру территориясе административ яктан Татарстан Республикасында, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә, шәһәрнең Киров районында урнашкан.

Проектлаштыру территориясе нигездә Казан шәһәренең Киров районындагы «Серебряный бор» торак комплексы аша «Несмелов урамыннан алып федераль әһәмияттәге М-7 “Волга” автомобиль юлына кадәр автомобиль юлы» линия объекты территориясен планлаштыру проектының кызыл

## Линия объектларының урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге

Урнашу урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектлары проектта юк.

## Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрендә линия объектлары составына керә торган капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрлары

Планлаштыру проектын эшләү кысаларында суүткәргеч насос станциясен төзү өчен участок каралган.

Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан «коммуналь хезмәтләр күрсәтү» (код 3.1.1) рөхсәт ителгән файдалану төрләре өчен җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрлары Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә билгеләнми.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 36 статьясындагы 4 өлешенең 3 пункты нигезендә линия объектлары биләгән яисә линия объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә шәһәр төзелеше регламентларының гамәлдә булуы кагылмый. Җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь) күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрлары билгеләнергә тиеш түгел.

Линия объектлары составына керә торган капиталь төзелеш объектлары катларының иң чик саны һәм (яисә) иң чик биеклеге мондый объектларны план буенча урнаштыруның һәр зонасы чикләрендә билгеләнми.

Линия объектлары составына керә торган капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыруның һәр зонасында төзелешнең, төзелергә мөмкин булган линия объекты составына керүче капиталь төзелеш объектын план буенча урнаштыру зонасы мәйданының әлеге зонаның бөтен мәйданына мөнәсәбәте буларак билгеләнә торган максималь проценты билгеләнми.

Проектлана торган линия объекты федераль яисә төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территорияләре чикләрендә урнашмый, димәк, федераль яисә төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан мондый объектларны планлаштырып урнаштыруның һәр зонасы чикләрендә линия объекты составына керүче капиталь төзелеш объектларының архитектура чишелешләренә карата таләпләр билгеләнми, мондый объектларның тышкы кыяфәтен чагылдыра торган төсләр чишелешенә таләпләр; мондый объектларның тышкы кыяфәтен билгели торган төзелеш материалларына таләпләр; мондый объектларның тышкы кыяфәтенә һәм (яисә) композициясенә, шулай ук тарихи җирлек төзелешенең силуэтына йогынты ясый торган күләм-пространство, архитектура-стилистик һәм башка характеристикаларына карата таләпләр күрсәтелми.

**Территорияне планлаштыру проектын әзерләгәндә гамәлдәге һәм төзелә торган, саклана торган капиталь төзелеш объектларын, шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә төзергә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын күрү зарурлыгы турында мәгълүмат**

Сууткәргеч төзелеше биналарны һәм корылмаларны җимерүне, шулай ук кешеләрне күчерүне күздә тотмый.

Проектлана торган линия объектлары, аларны план буенча урнаштыру зоналары чикләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларына тискәре йогынты ясау чыганагы булып тормый.

Линия объектын план буенча урнаштыру зонасына түбәндәге капиталь төзелеш объектлары эләгә:

- ВЛ 110 кВ лы электр тапшыруының һава линиясе;
- КЛ 6/10 кВ лы җир асты электр тапшыру кабель линиясе;
- сууткәргеч;
- хуҗалык-көнкүреш канализациясе (кадастр номеры 16:50:280303:8 булган җир кишәрлеге чикләрендә);

- янгыр канализациясе (параллель агымлы);
- автономияле җылылык челтәре (кадастр номеры 16:50:280303:8 булган җир кишәрлеге чикләрендә);
- газүткәргеч;
- автомобиль юллары.

Чаралар исемлегенә түбәндәгеләр керә:

- яңа төзелә торган корылмаларның, аларның нигезләренең һәм әйләнә-тирә грунт массивының торышын күзәтү, проект белешмәләреннән тайпылышларны үз вакытында ачыклау һәм үзгәрешләргә күзәтүләр үткәрү, мөмкин булган тискәре йогынтыларны кисәтү һәм бетерү чараларын эшләү, яңа төзелеш йогынтысы зонасындагы гамәлдәге корылмаларны саклап калуны, шулай ук әйләнә-тирә табигый мохитне саклауны тәэмин итү;

- төзелә торган объектның торышын, аның әйләнә-тирәдәге биналарга һәм корылмаларга, төзелеш чорында һәм аннан соңгы эксплуатацияләү елларында атмосфера, геологик, гидрогеологик һәм гидрологик мохиткә йогынтысын фаразлау, аларның торышындагы үзгәрешләрне бәяләү, җитешсезлекләрне вакытында ачыклау, тискәре процессларны булдырмау һәм бетерү, шулай ук кабул ителгән исәпләү ысулларының, проект чишелешләренең һәм фаразлау нәтиҗәләренең дөреслеген бәяләү.

Тикшерү буенча эшләрнең составы һәм күләмнәре һәр конкрет очракта гамәлдәге норматив документлар таләпләрен исәпкә алып һәм төзелә торган корылманың, шулай ук яңа төзелеш йогынтысы зонасындагы биналарның проект-техник документациясе белән танышуны исәпкә алып, эшләр программасы белән билгеләнә.

## Линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2025 елның 6 октябрендәге 01-02/6180 номерлы хаты нигезендә линияле объектны урнаштыру территориядә Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) Бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары һәм мәдәни мирас объекты (шул исәптән археологик мирас) билгеләренә ия объектлар юк.

Линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру каралмаган, чөнки объектны план буенча урнаштыру зонасы чикләрендә мәдәни мирас объектлары юк.

2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объект, шул исәптән археологик мирас объекты табылган очракта, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык һәм башка эшләр туктатып торылырга тиеш һәм мондый объект ачыкланган көннән алып өч көн эчендә Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетына табылган мәдәни мирас объекты турында язма гариза җибәрергә кирәк.

**Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

Проектлаштыру районында җирле әһәмияттәге махсус саклана торган табигый территорияләр, шулай ук Кызыл китапка кертелгән хайваннар һәм үсемлекләр юк.

Проект Россия Федерациясенең табигатьне һәм әйләнә-тирә мохитне саклау турындагы законнары таләпләрен исәпкә алып эшләнгән.

Төзелеш чорында әйләнә-тирә табигый мохиткә зыян салуның потенциаль мөмкинлеген киметү өчен 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында»гы федераль закон, 1999 елның 4 маендагы 96-ФЗ номерлы «Атмосфера һавасын саклау турында»гы федераль закон таләпләренә таянып, төзелеш үткәрү технологиясен сакларга һәм түбәндәге шартларны үтәргә кирәк:

- җирле әйләнә-тирә мохитне саклау органнары таләпләрен үтәү;
- төзелеш өчен бүлеп бирелә торган территория чикләрен мәҗбүри үтәү;
- эш урыннарын көнкүреш һәм төзелеш калдыклары өчен инвентарь контейнерлар белән тәэмин итү;
- машиналарны һәм механизмнарны махсус җиһазландырылган урыннарда юу;
- эш документациясе нигезендә территорияне тулысынча төзекләндерү эшләрен башкару.

Төзелеш-монтаж эшләрен башкарганда билгеләнгән тәртиптә расланган табигатьне саклау буенча норматив-техник документлар таләпләре үтәлергә,

шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклауның түбәндәге аспектлары һәм тәэсир итү факторлары исәпкә алынырга тиеш:

- су агымнарына йогынтыны минимальләштерү;
- тере табигатьнең яклауга мохтаҗ ресурсларын саклау;
- атмосферага зарарлы матдәләр чыгаруны минимальләштерү;
- калдыкларны җыюны һәм юк итүне оештыру;
- куркыныч материаллар белән эшне оештыру;
- тавыш йогынтысын минимальләштерү.

**Туфракны саклау чаралары**

Туфракны саклау буенча гомуми чаралар булып түбәндәгеләр тора:

- тискәре рельеф барлыкка китерүче уңайсыз процессларның үсешен, табигый өске агымның үзгәрүен булдырмау;
- төзелеш-монтаж эшләрен башкару һәм төзелеш хуҗалыгын урнаштыру өчен бүлеп бирелә торган территорияләр чикләрен мәҗбүри үтәү;
- эш урыннарын һәм төзелеш мәйданчыкларын көнкүреш һәм төзелеш калдыклары өчен инвентарь контейнерлар белән тәэмин итү;
- транспорт чараларының йөк ташу графикларына һәм транспорт чараларының йөк күтәрү сәләтенә туры китереп, әзерләнгән юллар буенча хәрәкәте;
- яклау-ныгыту чараларын башкару;
- җирләрне рекультивацияләү.

Төзелеш барышында бозылган барлык җирләр торгызылырга (рекультивацияләнергә) тиеш. Җир кишәрлекләре эш барышында, әгәр бу мөмкин булмаса, эш тәмамланганнан соң бер елдан да соңга калмыйча, файдалану өчен яраклы хәлгә китерелә. Бозылган җирләрне торгызу буенча барлык эшләр бүлеп бирелгән территория чикләрендә башкарыла.

**Атмосфераны саклау буенча чаралар**

Капиталь төзелеш чорында атмосфера һавасына түбәндәге эшләр барышында йогынты ясала:

- транспорт, төзелеш техникасы эшләгәндә;
- эретеп ябыштыру эшләрен башкарганда;
- металлны газ белән кискәндә;
- лак-буяу материалларын кулланганда.

Атмосфера һавасын саклау чаралары төзелеш-монтаж эшләре алып барыла торган территориядә эшләүче машиналардан һәм механизмнардан чыккан зарарлы матдәләр белән һава бассейнының пычрануын булдырмауга юнәлдерелгән. Атмосферага зарарлы матдәләр чыгаруның әйләнә-тирә мохиткә

тискәре йогынтысы дәрәҗәсен киметә торган чаралар исәбенә түбәндәгеләрне кертергә кирәк:

- төзелеш машиналары һәм механизмнарының, шулай ук автотранспорт чараларының техник халәтен зыянлы матдәләр чыгару буенча норматив таләпләргә туры китерү һәм нормада тоту;
- төзелеш машиналарына, механизмнарына һәм автотранспортка техник тикшерүләр үткәрү һәм профилактик хезмәт күрсәтү;
- эчке яну двигательләренең газ чыгаруын контрольдә тоту буенча техник тикшерү үтмәгән машиналарны эшкә кертмәү;
- ягулык куллануны 10-15 процентка киметергә һәм зарарлы матдәләр чыгаруны киметергә мөмкинлек бирә торган оптималь эш режимнарын тәэмин итү;
- аз күкертле һәм этилсыз ягулык төрләрен куллану;
- машиналарны, механизмнарны һәм автотранспортны ягулык белән тәэмин итүне махсус тарату пистолетлары белән мәҗбүри җиһазландырылган ягулык салу җайланмалары ярдәмендә гамәлгә ашыру;
- әйләнә-тирә мохиткә очучан компонентлар чыгаруны булдырмый торган герметик схемалар кулланып, барлык транспорт чараларына ягулык-майлау материаллары ташу һәм ягулык салу;
- санап үтелгән пунктларның үтәлеше буенча экологик контрольне гамәлгә ашыру.

**Үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына йогынтыны киметү чаралары**

Үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына тискәре йогынтыны киметү һәм булдырмау өчен капиталь төзелеш барышында түбәндәге табигатьне саклау таләпләре үтәлергә тиеш:

- төзелеш-монтаж эшләрен башкару бүленгән җир мәйданнары белән катгый чикләнергә тиеш;
- төзелеш техникасын күчерү махсус билгеләнгән юл чикләрендә генә рөхсәт ителә;
- янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү;
- территориянең ягулык-майлау материаллары белән пычрану мөмкинлеген юкка чыгару;
- эрозия процесслары үсешен булдырмау;
- эшчеләрнең, хезмәт күрсәтү персоналының, инженер-техник хезмәткәрләрнең һәм җитәкчеләрнең контрактларында аучылыкны, агач-куак үсентеләрен рөхсәтсез кисүне тыю турындагы статья кертү.

Санап үтелгән чараларны гамәлгә ашыру, шулай ук капиталь төзелеш тәмамланганнан соң рекультивация эшләрен башкару капиталь төзелеш чорында табигатькә һәм саклана торган территорияләрдә яшәүчеләргә тискәре йогынтыны минимумга кадәр киметергә мөмкинлек бирәчәк.

**Бозылган җирләрне рекультивацияләү чаралары**

Вакытлыча хуҗалык урнаштыру өчен территорияне һәм эшләр башкару зонасын төзү-монтаж эшләре башланганчы рәсмиләштерергә кирәк. Эшләрне башкарганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

- территориянең төзелеш материаллары, калдыклар һәм чүп-чар белән чүпләнүе, агулы матдәләр белән пычрануы; ягулык-майлау материалларының түгелүе һәм агып чыгуы;
- транспорт чараларының эш башкару проектында билгеләнмәгән ирекле маршрутлар буенча йөрүе.

Төзелеш-монтаж эшләре тәмамланганнан соң җирләрдә рекультивация ясала. Техник рекультивация төзелешнең йомгаклау этабы булып тора. Биологик рекультивация елның җылы вакытында, кар катламы киткәннән соң үткәрелә.

Капиталь төзелеш тәмамланганнан соң, рекультивация үткәрелә башлаганчы, башкарыла торган эшләрнең проект һәм норматив документлар таләпләренә туры килүен системалы күзәтү һәм тикшерү гамәлгә ашырыла.

## Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм гражданнар оборонасы буенча чараларны гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

**Гомуми нигезләмәләр**

Объектны эксплуатацияләү һәм төзү чорларында гражданнар оборонасы (алга таба – ГО) таләпләрен тәэмин итү, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү чаралары объектны төзүнең һәм эксплуатацияләүнең барлык этапларында мәҗбүри булган төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре составында каралган. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезләмәләре нигезендә гражданнар оборонасын тәэмин итү, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү буенча проект документациясе бүлеген эшләү таләп ителми.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1998 елның 3 октябрендәге 1149 номерлы «Территорияләрне гражданнар оборонасы буенча төркемнәргә

кертү тәртибе турында»гы карары нигезендә проектлана торган территория түбәндәге параметрлар белән характерлана:

- гражданнар оборонасы буенча территория категориясе – категорияләнмәгән;

- 165.1325800.2014 номерлы «Гражданнар оборонасы буенча инженер-техник чаралар» кагыйдәләр җыентыгы нигезендә проектлана торган территория мөмкин булган җимерелү, куркыныч химик зарарлану һәм куркыныч радиоактив зарарлану мөмкинлеге булган зоналардан читтә урнаша.

**Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү**

Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүнең гомуми хокукый, икътисади һәм иҗтимагый нигезләре 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы «Янгын куркынычсызлыгы турында»гы федераль закон белән билгеләнә. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә янгын куркынычсызлыгы системасын куллану юлы белән ирешелә, ул янгыннарга каршы көрәшкә юнәлдерелгән көчләр һәм чаралар, шулай ук хокукый, оештыру, икътисади, социаль һәм фәнни-техник характердагы чаралар җыелмасы буларак аңлашыла.

Линия объектында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасының төп функцияләре түбәндәгеләр:

- янгыннан саклау хезмәтен булдыру һәм аның эшчәнлеген оештыру;
- янгын куркынычсызлыгы чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;
- объектта янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә хокукларны, бурычларны һәм җаваплылыкны гамәлгә ашыру;
- янгын куркынычсызлыгын фәнни-техник яктан тәэмин итү;
- янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә мәгълүмати ярдәм күрсәтү;
- янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшләр башкару;
- янгыннарны сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару;
- янгыннарны һәм аларның нәтиҗәләрен исәпкә алу;
- янгынга каршы махсус режим билгеләү;
- эксплуатацияләүче оешма хезмәткәрләре тарафыннан янгын-техник минимумын өйрәнү.

Проектлаштыру объектында штаттан тыш хәлләр очрагында янгыннан саклау хезмәтенә хәбәр итү һәм чакыру схемасын эшләргә кирәк.

**Техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы**

Проектлана торган территориядә аварияләр килеп чыгуның иң ихтимал урыннары булып инженерлык челтәрләре тора (электрүткәргеч һава линияләре өзелү һәм җир асты электр үткәргечләренең зарарлануы).

Автотранспортта гадәттән тыш хәл барлыкка килүнең сәбәбе булып шартлау-янгын куркынычы булган матдәләрне (автомобиль цистерналарында сыекландырылган углеводород газы пропан һәм бензин) транспорт белән ташу мөмкин булган транспорт коммуникацияләрендәге аварияләр торырга мөмкин. Автотранспортта иң куркыныч авария – автоцистернаны герметиксызландырганда бензин түгелү, ә иң ихтималы – 50 литрлы бензин багына зыян килү нәтиҗәсендә бензин түгелеп, шартлау һәм янгынга китерү мөмкинлеге.

Табигый афәтләр вакытында (бозлавык, кар көртләре, су басулар, көчле яңгырлар) аварияләр ихтималы арта. Мондый очракта автотранспорттагы аварияләрнең иң куркыныч һәм иң ихтимал сценарийлары вакытында зарарлы факторларның тәэсир итү зоналары:

- автоцистерна: түгелгән сыеклык яну (максималь зона) – 37,12 м; шартлау (максималь зона) – 148,72 м;

- җиңел автомобиль (50 л): түгелгән сыеклык яну (максималь зона) – 3,56 м; шартлау (максималь зона) – 22,16 м.

Планлаштыру проекты территориясе буенча гамәлдәге газ бүлү үткәргечләре уза. Урта һәм югары басымлы газүткәргечләр 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы «Куркыныч җитештерү объектларының сәнәгать иминлеге турында»гы федераль закон нигезендә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгарга мөмкин булган куркыныч җитештерү объектларына керә.

Вертикаль факеллы янудагы җылылык нурланышының интенсивлыгы (иң ихтимал авария) Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2024 елның 26 июнендәге 533 номерлы «Җитештерү объектларында янгын чыгу куркынычының исәп зурлыкларын билгеләү методикасын раслау турында»гы әмере нигезендә исәпләнде.

Брезент кием кигән кеше өчен куркынычсыз ераклыкта (4,2 кВт/кв.м) вертикаль факел януыннан җылылык нурланышының интенсивлыгы түбәндәгечә булачак:

- урта басымлы газүткәргеч Ø89 Г2 – 19,1 м;
- урта басымлы газүткәргеч Ø250 Г2 – 43,3 м;
- урта басымлы газүткәргеч Ø300 Г2 – 49,9 м;
- югары басымлы газүткәргеч Ø200 Г4 – 55,4 м;
- югары басымлы газүткәргеч Ø300 Г4 – 76,0 м;
- югары басымлы газүткәргеч Ø500 Г4 – 112,7 м.

**Табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы**

Проектлаштыру территориясендә төп процесслар түбәндәгеләр:

- сезонлы туң төшү һәм туфракның туңып күтәрелүе;
- су басу;
- авышлык процесслары;
- карст.

Сезонлы туң төшү һәм туфракның туңып күтәрелүе;

115.13330.2016 номерлы «Куркыныч табигый йогынтылар геофизикасы» кагыйдәләр җыелмасы нигезендә эш участогында туфракның туңып күтәрелү процессын уртача куркыныч дип классификацияләргә тәкъдим ителә. Туң күтәрелүеннән инженерлык саклану өчен туң күтәрелүгә каршы конструктив чаралар тәкъдим ителә.

Су басу

Көтелә торган техноген йогынтыларга бәйле потенциаль су басуның төп факторлары түбәндәгеләр:

- комлы туфракларда түбән үткәрүчәнлекле катламнарның булуы;
- эш урынының рельеф үзенчәлекләре (җир өсте агымы тупланып торган сөзәк участоклар, түбән урнашкан территорияләр);
- техноген факторлар (мәсәлән, су үткәрү коммуникацияләре булу, карны саклау);
- территорияне планлаштыру нәтиҗәсендә җир өсте агымының үзгәрүе.

Куйбышев сусаклагычында җир өсте суларының җайга салынган режимы аркасында, җир асты суларының күтәрелүе көтелми.

Дренаж системасы булмау, фильтрлау коэффициенты түбән булган балчыклы грунтлар аша үтеп керүче яңгыр һәм кар суларының агып төшүен тоткарлау исәбенә фундаментлар салу тирәнлекләрендә техноген чыгышлы су белән капланган горизонт формалашуга китерергә мөмкин. Су ташучы коммуникацияләрдән техник сулар агып чыгу шулай ук «өске агым» тибындагы грунт сулары барлыкка килүгә китерергә мөмкин.

Грунт суларының куркыныч йогынтысын бетерү максатында түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

- җир өсте суларын яңгыр корылмалары системасына яки территориядән (корылмалар йогынтысы зонасыннан) чыгаруны оештыру;

- суүткәргеч коммуникацияләрдән агып чыгуларны булдырмау чаралары (шул исәптән туңу тирәнлеген исәпкә алып, су агызу системаларын проектлау һәм урнаштыру);

- сыйфатлы материаллар куллану; төзелеш техникасы системаларының зарарлануын һәм деформацияләнүен булдырмау; хезмәт күрсәтү өчен керү мөмкинлеге булу.

Авышлык процесслары

Инженер-рекогносцировка тикшеренүе барышында авышлык процессларының визуаль чагылышлары (шәрәлекләр, җир ишелү җисемнәре, ауган агачлар, биналарның һәм корылмаларның деформацияләре) ачыкланмаган. Җирле халыктан сораштыру шулай ук тикшерү участогы чикләрендә әлеге процессның булмавын раслады.

Карст

Космос сурәтләрен, геодезик рәсемнәрне, топографик карталарны анализлау барышында эзләнүләр территориясе тирәсендә (2 км радиуста) рельефның тискәре локаль формалары ачыкланды. Рекогносцировка тикшеренүе нәтиҗәләре бу мәгълүматны раслады.

Космос сурәтләрен, 1961 елдан алып 2023 елга кадәрге чорда тикшерелгән участокның тарихи сурәтләрен анализлау, рекогносцировка тикшеренүе, эзләнүләр территориясе тирәсендәге җирле халыктан сораштыру барышында (2 км радиуста) карст-суффозия процессларның яңа өслек чагылышлары теркәлмәде.

Проектлаштыру участогы карст-суффозия мөнәсәбәтендә алдан ук куркынычсыз категориягә карый.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, карбонат карсты таралган районнарда карст ясалу тизлеге корылманы эксплуатацияләү вакытыннан күпкә артып китә.

Объектны төзү һәм эксплуатацияләү стадияләрендә түбәндәге чараларны башкарырга тәкъдим ителә:

- контроль-мониторинг;

- оештыру-техник.

Мөмкин булган куркыныч метеорологик күренешләр (көчле җилләр, давыллар һ.б.) проектлана торган объектка йогынты ясамаячак, проектлана торган объектны төзү һәм аны эксплуатацияләү чорында гидрометеорологик характеристикаларның үзгәрүе көтелми.